# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы тарафыннан<br>2013 елның 28 мартында<br>кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1), 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки туктату – Федераль законның 30 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда, торак пунктлар чикләре эчендәге региональ, җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата халыкара спорт чараларын уздыру чорында да билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы<br>Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль<br>2013 елның 11 апреле<br>№ 27-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ГОМУМИ БҮЛЕК<br>ОБЩИЙ ОТДЕЛ